5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Назипова А. Ф. Укучыга тәрбия бирүдә гаилә һәм мәктәп хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2025. № 1 (24).
URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2025/03/2025_1_nazipova.pdf

УДК 37.02

**Алия Фаридовна Назипова**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 60 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Яр Чаллы, Рәсәй

# Укучыга тәрбия бирүдә гаилә һәм мәктәп хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре

***Аннотация:*** Мәкаләдә гаилә һәм мәктәп арасындагы үзара хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре, формалары һәм ысуллары чагылдырыла, әлеге хезмәттәшлекнең максатлары һәм нәтиҗәсе күрсәтелә. Гаилә тәрбиясенең асылы һәм эчтәлеге, аның укыту-тәрбия эшенә, шулай ук баланың шәхес булып формалашуына йогынтысы ачыклана. Галим-педагогларның тәрбия өлкәсенә караган фикерләре яктыртыла.
***Төп сүзләр***: гаилә һәм мәктәпнең үзара бәйләнеше; гаилә тәрбиясе; гаилә педагогикасы; тәрбия потенциалы

**Aliya F. Nazipova**
Teacher of Tatar language and literature of the first category, Secondary school No. 60, Naberezhnye Chelny, Russia

# The Main Areas of Interaction Between Family and School in the Education of Student

***Abstract:*** The article reflects the main directions, forms and methods of interaction between family and school, indicates the goals and results of this cooperation. The article reveals the essence and content of family education, its impact on educational work, as well as on the formation of a child's personality. The views of scientists and teachers on the field of education are highlighted.
***Keywords:*** family and school interaction; family education; family pedagogy; educational potential

Мәктәптә һәм гаиләдә тәрбия эшенең кимүе нәтиҗәсендә, гаиләгә психологик-педагогик ярдәм булмау, мәктәп администрациясе, педагоглар, ата-аналар арасында эшчәнлек оештыруның түбән дәрәҗәдә булуы, икътисадый үзгәртеп кору шартларында бөтен игътибарны мәктәпләрдә тәрбия эше сыйфатын яхшыртуның, гаиләне укыту-тәрбия эшенә катнашуга җәлеп итүнең яңа юлларын эзләү мәсьәләләренә юнәлтергә кирәк.

Тәрбия — еш кына комплекслы, системалы якын килүне, бер-берсенә каршы килүче компонентларны бәйләүне таләп итә торган катлаулы һәм дәвамлы процесс. Шуңа күрә тәрбияләргә өйрәнергә кирәк. Шул уңайдан Р.Фәхреддиннең сүзләрен искә төшерү урынлы: “Тәрбия — акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер… Сабанчы вә бакчачылар орлык чәчмәстән вә җимеш икмәстән элек җирләрен никадәр игътибар белән йомшартулары, чүп вә бозык үләннәрнең хәтта тамырларына кадәр чыгарып ташлаулары мәгълүмдыр. Бу төркемнән бөек вә гүзәл кеше итәчәк кемсәләрне сабый вакытларында тәрбия итү тиеш килер. Тәрби-

© Назипова А. Ф., 2025

ясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия — иң кирәкле бер эш булачактыр" [1, 43 б.].

Тәрбия турында сөйләгәндә, без шуны ассызыкларга тиешбез: бу — кеше яшәешенең аерылгысыз өлеше. Тәрбия процессында кеше җәмгыять әгъзасы, әлеге тарихи вәзгыятьнең катнашучысы булып кына калмый, ул үзенең кешелек асылын тормышка ашыра. Тәрбия — барыннан да элек балага "Мин кем?" һәм "Нәрсә өчен яшим?" сорауларына җавап табарга ярдәм итү процессы. Башка сүзләр белән әйткәндә, бу — формалашып килүче шәхеснең үз тормышын сайлавына бер юнәлеше. Моннан тыш, шәхес формалашуының максатлары һәм чаралары җәмгыять яки дәүләт таләпләреннән түгел, ә үз асылыннан килеп чыгуын танырга кирәк. Баланы бу агымга кертергә тырышырга ярамый, ә киресенчә, әлеге процессны аның хәзерге тормышына яраклаштырырга кирәк.

Бу мөһим бурычны тормышка ашыруда төп рольне мәктәп, гаилә һәм җәмәгатьчелекнең үзара хезмәттәшлеге уйнарга тиеш. Педагогларның һәм ата-аналарның уртак эше — тәрбия мохитен гуманизацияләүгә, мәктәп һәм гаилә эшчәнлегенең гомуми стратегиясен эшләүгә, уртак эш программаларын билгеләүгә, педагогик эшчәнлекне камилләштерүгә юнәлдерелгән партнерлык эшчәнлеге ул. Шуңа күрә укучыларның шәхесен формалаштыруда һәм әхлакый, рухи, эстетик, патриотик, экологик сыйфатларны тәрбияләү процессында гаилә белән мәктәпнең үзара килешеп эшләве зарур. Үзара хезмәттәшлек — уртак максатларга һәм нәтиҗәләргә ирешү, катнашучылар өчен әһәмиятле булган проблемалар яки бурычларны чишү буенча оештырылган эшчәнлек. Кеше өчен бу әйләнә-тирә дөньяның төрле объектлары белән үзара хезмәттәшлеккә омтылуында чагыла. Үзара тәэсир итешү аша кеше табигый һәм иҗтимагый күренешләрне, закончалыкларны, процессларны аңлый, әйләнә-тирәдәге чынбарлыкка ориентлаша, үзенең фикерләү һәм үз-үзен тотышы ысулларын билгели.

Педагогика фәне, педагогик үзара тәэсир итешү төшенчәсен кулланып, коммуникатив гамәлләрне системалы рәвештә тормышка ашыруны күздә тота. Аның төп юнәлешләре булып:

- укучыларның сәләтләрен ачу һәм педагогик коллективның иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен мәктәп мөмкинлекләреннән файдалану;
- укучыларның дәрестә һәм дәрестән тыш вакытта танып белү һәм иҗади эшчәнлеген стимуллаштыру;
- педагогларның фәнни-тикшеренү һәм иҗади эшчәнлеген стимуллаштыру;
- укытучының үз һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләрен системалы рәвештә бәяләве;
- гаилә һәм мәктәп эшчәнлегендә ата-аналарның уртак хезмәтен арттыру;
- мәктәпнең мәгълүмати пространствосын булдыру һ. б. тора.

Белем бирү процессын катлаулы педагогик хезмәттәшлек системасы буларак тәкъдим итәргә кирәк. А. С. Макаренко ассызыклаганча: "Тәрбия — киң мәгънәдә социаль процесс ул. Барысы да тәрбияли: кешеләр, әйберләр, күренешләр, ләкин барыннан да бигрәк — кешеләр. Алар арасында беренче урында — ата-аналар һәм педагоглар". Мәктәп ата-анадан алган хәзинәне алыштыра алмый. Педагоглар, профессиональ мөмкинлекләрен кулланып, мәктәптән тыш алган уңай йогынтыны баета һәм көчәйтә, аны үзләренең тәрбия эшчәнлеге системасына кертә, шулай ук мөмкин булган чикләрдә тискәре йогынтыны нейтральләштерә һәм шулай эшләргә тиеш тә.

Мәгариф системасы алдында тәрбия эшчәнлегенең барлык субъектлары өчен дә (педагоглар, ата-аналар һәм балалар) уртак булган бурычларны куярга һәм шул рәвешчә аларны үзара хезмәттәшлеккә берләштерергә кирәк. Гаилә — бертөрле кыйммәтләрне, мәктәп икенчеләрен күрсәткәндә, төрле укытучы төрле якка юнәлдергәндә бала каршылык эчендә калачак. Ул ориентларда буталачак, бу еш кына эчке гармониянең югалуына һәм психологик халәтнең бозылуына китерә.

Һичшиксез, балаларны тәрбияләүдә һәм укытуда иң актив субъектларның берсе бу-

лып мәктәп тора. Аның эшенең нәтиҗәлелеге аермачык, үсеп килүче буынга йогынтысы бәхәссез. Әмма мәктәп гаиләнең тәрбия потенциалын күтәрү кебек әһәмиятле аспектына кагылса, педагогик эшчәнлекнең, гаилә һәм мәктәпнең тәрбия эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күп тапкырлар артачак. Нәкъ тә менә гаилә балага җитлеккән шәхескә әверелергә ярдәм итә. Гаиләдәге психологик карашлар, баланың өлкәннәр белән үзара бәйләнеш характеры, гаилә микроклиматы — болар барысы да баланың шәхесен формалаштыра. Психологлар һәм педагоглар баланың "үзлеген" формалаштыру үзенчәлекләре турында ничек кенә бәхәсләшмәсеннәр, ләкин ата-аналарның йогынтысын берсе дә инкарь итә алмый.

Гаилә баланың шәхси һәм социаль тотрыклылыгын формалаштыруда мөһим фактор булып тора. Ул, җәмгыятьнең беренчел ячейкасы буларак, кече социаль төркемне тәшкил итә, анда яңа кеше үзенең беренче тормыш мәктәбен уза. Бала өчен ата-аналар — аның беренче укытучылары һәм тәрбиячеләре. Аларның формалашып килүче шәхескә йогынты ясау көче гаять зур. Балага йогынтының нигезе булып ата-ананың риясыз мәхәббәте һәм таләпчәнлеге тора. Бала бу мәхәббәткә һәм кайгыртучанлыкка әти-әнисенә тирән ярату хисе белән җавап бирә. Ул аларның өстенлеген һәм абруен таный, аларга иярергә, охшарга омтыла. Гаилә — пассив йогынты ясау объекты түгел, ә шәхес формалашуның актив субъекты, педагогик эшчәнлекнең өстенлекле өлкәсе. Мәктәп — шәхес тәрбияләүдә гаилә партнеры.

Җәмгыять үсешенең һәр тарихи этабында гаилә педагогикасы, яңалыкларның иң яхшыларын үз эченә алып, камилләште, шул ук вакытта үткәндәге иң яхшы тәҗрибәне дә саклап калды. Бу тәҗрибә А.С. Макаренко, Н.Ф. Голованова, В.А. Сластенин һ.б. хезмәтләрендә яхшы күрсәтелгән. Бу галимнәр тарафыннан формалаштырылган тәрбияви бурычлар, киң таралган хаталарның сәбәпләре гаилә педагогикасы теориясе өчен зур әһәмияткә ия. Галимнәр ата-аналарны кешелек дөньясы алдында, ә иң мөһиме, балалары алдында булган җаваплылыкны танырга чакыра. Моның өчен алар күренекле педагогларның идеяләре, алдынгы тәҗрибәләр белән танышырга тиеш.

А.С. Макаренко яктырткан педагогик проблемалар арасында гаилә тәрбиясе теориясе аерым урын алып тора. Ул гаиләне коллектив буларак карый, анда ата-аналар башбаштаклыгына урын булырга тиеш түгел. Галим-педагог күрсәткәнчә, гаилә ул — күпкә көчле тәрбия үзәге, ул без уйлаганнан да күбрәк эшчәнлек күрсәтә ала. Гаилә тәрбиясенең авторитарлыгын инкарь итеп, А.С. Макаренко ата-аналарның чын авторитетының әһәмиятен дәлилли, аның кайбер гаиләләрдә бүгенге көндә дә гадәттән тыш чыдам булып чыккан һәм көнкүрештә булган ялган төрләрен тасвирлый. Ата-ананың үз-үзен тотышы — иң беренче хәл иткеч фактор. Балага аның белән сөйләшкәндә, аңа акыл өйрәткәндә яки аңа боерык биргәндә генә тәрбия бирелә дигән сүз дөрес түгел. Ата-аналар баланы тормышларының һәр моментында, хәтта бөтенләй өйдә булмаган чакларында да тәрбияләүләрен аңларга тиеш. Ничек киенүләре, башка кешеләр турында ни сөйләүләре, ничек шатланулары яки кайгырулары, аларны чолгап аган кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә булулары, ничек көлүләре, ничек газета укулары — менә боларның барысының да бала өчен әһәмияте бар икәнлеген күрсәтә галим [2, 78 б.].

Гаилә еш кына социаль педагогика һәм тәрбиянең гомуми теориясе төшенчәләре юнәлешендә анализлана. Н.Ф. Голованова фикеренчә, тәрбия һәр балада кыйммәтләрнең, тормыш перспективаларының, максатларның чынбарлыгын тою тудырырга тиеш. Аларга иярү, ярдәм итү һәм аларны яклау теләге гаиләдә туарга һәм мәдәни бергәлек тарафыннан хупланырга тиеш. Тәрбияләүнең төп максаты — һәр тәрбияләнүченең уникальлеген һәм үзенчәлеген, аның социаль хокукларын һәм ирекләрен тану. Шәхес үсеше гомер буена, барыннан да элек, социализация процессында бара. Тәрбия социализация өчен гамәли мохит тудыра, аның рухи һәм предметара әйләнә-тирәсен баета һәм шул ук вакытта үзе конкрет тормыш эчтәлеге белән

тулылана. Бу балалар һәм яшьләрнең социаль-мәдәни кыйммәтләргә тартылган тәрбиянең төрле ситуацияләрендә өлкән һәм яшь буынның ассоциатив һәм күпкырлы хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә килеп чыга [3, 138 б.].

Башка социаль институтлардан аермалы буларак, В.А. Сластенин фикеренчә, хәзерге заман гаиләсе турыдан-туры үзгәртеп кору йогынтысына бирешми. Гаиләне мораль, психологик яктан яңарту процессы озаграк, каршылыклырак һәм катлаулырак. Гаиләдә яңа мөнәсәбәтләрне, яңа әхлакны раслау икътисадый өлкәгә караганда акрынрак темплар белән гамәлгә ашырыла. Чөнки гаиләне үзгәртеп коруда төп социаль-икътисадый факторлардан тыш, башка факторлар — биологик, психологик, демографик факторлар да катнаша. Моның белән гаилә психологиясендә искенең тотрыклылыгы һәм чыдамлыгы сәбәбен аңлатырга мөмкин. Аерым алганда, гаилә үсешен фаразлауда кыенлыклар да шуның белән аңлатыла. Гаилә тормышы күп яклы мөнәсәбәтләр белән характерлана: социаль-биологик, хуҗалык-икътисадый, әхлакый, психологик. Гаилә үсешендәге һәр этап бер функциянең югалуы һәм икенчесенең барлыкка килүе, аның әгъзаларының социаль эшчәнлеге масштабларының һәм характерының үзгәрүе белән бәйле. Гаилә җәмгыятькә һәм кешегә карата мөһим иҗтимагый әһәмиятле функцияләрне башкара [4, 310 б.].

Гаилә тәрбиясе сәнгате ата-аналарның балаларда үз-үзләрен таба белүен, аларны үзләре белән ияртүләрен үз эченә ала. Ул кабатлануны түзеп тормый, чөнки балалар табигате буенча кабатланмас. Һәр баланың үз индивидуаль үзенчәлекләре бар, алар белән исәпләшергә кирәк. Хәзерге яшүсмер тормышта үз урынын табарга һәм уңышка ирешергә омтыла. Педагогның бурычы — аңа бу юлда ярдәм кулы сузу. Моның өчен уртак эшчәнлек, конструктив эшчәнлек кыры булдыру зарур. Бу очракта укучының хәтерендә белем генә түгел, яраткан укытучысы турында якты истәлекләр, матур мөнәсәбәтләр дә, киләчәкне төзү теләге һәм осталыгы да уелып кала.

Соңгы елларда гаиләләр коррекция белән шөгыльләнүче учреждениеләр ярдәменнән ешрак файдалана башладылар. Бу — психологик консультация хезмәте, поликлиникаларга беркетелгән логопед кабинетлары, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның махсус аерым төркемнәре өчен учреждениеләр һ.б. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияли торган гаиләләр мәктәп белән күзгә күренми торган җепләр белән бәйләнгән: ата-аналар баланың заманча мәктәп таләпләренә ни дәрәҗәдә әзер булуы турында борчыла һәм бу таләпләргә ориентлаша башлый. Аннары мәктәпне сайлау, балаларны анда укырга әзерләү чоры башлана.

Хәзерге гаилә баланы башка тәрбия институтларыннан аерып тәрбияли алмый: бала мәктәпкәчә учреждениегә йөри, аннары мәктәптә, сәнгать тәрбиясе түгәрәгендә яки студиясендә шөгыльләнә, спорт секциясенә йөри һ. б. Гаилә тәрбиясенең универсаль һәм алыштыргысыз булуына карамастан, ул шәхеснең гармонияле һәм төрле яклы үсеше өчен шартлар тудыра алмый. Шуңа күрә гаилә тәрбиясен җәмгыять тәрбиясе белән алмаштыру турында сүз бармый, ә ата-аналарның һәм профессиональ педагогларның хезмәттәшлеге күздә тотыла.

Шулай итеп, заманча гаилә тәрбиясе шәхес формалашуның автоном факторы буларак каралмый. Киресенчә, өйдә тәрбияләүнең нәтиҗәлелеге, әгәр ул башка тәрбия институтлары системасы белән тулыландырылса, арта гына. Хәзерге заман шартларында яшь кешенең шәхес булып формалашуына уңай йогынты ясый торган тәрбияви кыйммәтләрне эзләргә һәм педагогик эшчәнлеккә кертергә кирәк. Кызганычка каршы, бүгенге көндә мәктәп практикасында көнбатыш белем бирү моделе тарала, ул мәктәпне тәрбияләүче институт буларак кабул итми, ә аннан бары тик белемнәрне тапшыруны гына көтә.

Гаилә һәм мәктәпнең үзара хезмәттәшлеген оештыру түбәндәгеләрне күзаллый:

- гаиләне өйрәнү — укучыларның гаиләләре характеристикаларын төзү, гаиләне өйрәнү буенча диагностик эшләр оештыру, арадаш һәм соңгы нәтиҗәләрне анализлау;

- гаиләләрне әхлакый потенциал дәрәҗәсе буенча төркемләү һәм балаларга йогынты ясау мөмкинлекләрен, гаиләдә тәрбияләүнең уңай тәҗрибәсен ачыклау;
- гаиләнең әхлакый яшәү рәвешен формалаштыруда, наркоманияне профилактикалауда һәм диагностикалауда, балаларда һәм яшүсмерләрдә башка тискәре күренешләрне кисәтүдә ата-аналарга ярдәм күрсәтү;
- төрле этапта ата-аналар белән хезмәттәшлек итү — гаилә тәрбиясе шартларын һәм микроклиматын, балаларның һәм ата-аналарның индивидуаль үзенчәлекләрен өйрәнү, ата-аналарга психологик-педагогик агарту оештыру, ата-аналар белән массакүләм чаралар системасын булдыру, гаилә тәрбиясенә педагогика традицияләрен кертү.

Гаилә һәм мәктәпнең үзара хезмәттәшлеген оештырганда бу хезмәттәшлекнең максатын һәм педагогик шартларын билгеләү зарур, аларны үтәү аның нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итәчәк. Үзара хезмәттәшлекнең максаты — гаиләне мәктәп эшчәнлегенә җәлеп итү, бала шәхесен үстерүдә үзара аңлашуны һәм бер юнәлешлелекне тәэмин итү. Мәктәп һәм гаилә арасында үзара хезмәттәшлекнең максатлары һәм педагогик шартлар үзара хезмәттәшлекне оештыруда төп структур элементлар булып торалар. Ә куелган максатларга ирешү чарасы булып үзара хезмәттәшлек формаларын һәм методларын сайлау алга килеп баса.

Күп кенә галимнәр үзара тәэсир итешү формаларын индивидуаль яктан һәм төркемнәргә бүлеп карыйлар. Мәктәп һәм гаилә арасында үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларына түбәндәгеләр керә:

- гомуми һәм сыйныф җыелышлары;
- тематик конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, балага тәрбия бирү тәҗрибәсе белән урталашу буенча диспутлар һәм дискуссияләр;
- белгечләр белән берлектә сораулар һәм җаваплар кичәсе;
- ата-аналар өчен ачык ишекләр көне;
- билгеле вакыт аралыгында ата-аналарның сыйныфка килеп, балаларны күзәтүе;
- педагоглар да, гаилә әгъзалары да әзерли торган презентацияләр;
- ата-аналарны предмет газеталарын эшләргә, текст һәм фотоматериаллар күргәзмәләре бизәүгә, күрсәтмәләр әзерләүгә җәлеп итү;
- ата-аналарны мәктәп түгәрәкләренә җәлеп итү;
- ата-аналарның сыйныфтан тыш һәм мәктәптән тыш эшләрне әзерләүдә һәм башкаруда катнашуы.

Мәктәп һәм ата-аналар арасындагы үзара хезмәттәшлекнең индивидуаль формалары: ата-аналар һәм гаиләнең башка әгъзалары белән индивидуаль әңгәмәләр үткәрү, баланың яшәү шартлары белән танышу өчен өйләренә йөрү, гаилә әгъзаларыннан сораулар алу, гаиләнең социаль картасын төзү, торак-көнкүреш һәм тәрбия шартларын тикшерү, гаилә проблемалары һәм балаларны тәрбияләү проблемалары буенча консультацияләр үткәрү.

Кайбер галимнәр фикеренчә, педагоглар һәм ата-аналарның уртак эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып түбәндәгеләр санала:

- укучылар тормышының танып белү өлкәсен күзәтү;
- балаларның физик сәламәтлегенә ярдәм итү;
- укучыларның өстәмә белем алуын һәм иҗади потенциалын үстерү, социаль ярдәм күрсәтү;
- сәләтле балаларга ярдәм итү;
- ата-аналарга укыту-тәрбия процессының эчтәлеге турында мәгълүмат бирү;
- ата-аналар комитеты белән хезмәттәшлек итү;
- ата-аналарның һәм укучыларның уртак эшчәнлеге;
- ата-аналарга балаларны тәрбияләү, укытуның барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү;
- сәламәтлек мәсьәләләре белән шөгыльләнүче иҗтимагый оешмаларда эшли торган ата-аналар белән аралашу.

Үзара хезмәттәшлекне тормышка ашыру өчен эчтәлекне, формаларны һәм методларны мәктәп сайлый. Алар иҗтимагый

карашларга һәм омтылышларга, шулай ук бу этапта мәктәп һәм гаилә алдында торган конкрет бурычларга бәйле. Гаиләне педагогик яктан яктыртуның мөһим аспекты булып ата-аналарның педагогик культурасын күтәрү тора. Ата-аналарның педагогик культурасы аларның тәрбия эшчәнлегенең нигезе булып санала. Балаларны өйдә тәрбияләүнең уңышы һәм нәтиҗәлелеге ата-аналарның педагогик культура дәрәҗәсеннән бәйле. Ул берничә компонентны үз эченә ала: тәрбия өчен җаваплылыкны аңлау, балаларны үстерү, тәрбияләү, укыту турында тиешле белемнәр булу; гаиләдә балаларның яшәешен һәм эшчәнлеген оештыруның, тәрбия эшчәнлеген гамәлгә ашыруның гамәли күнекмәләре; башка тәрбия институтлары (мәктәпкәчә учреждение, мәктәп) белән нәтиҗәле элемтә.

Гаилә тәрбиясе практикасы күрсәткәнчә, күпчелек ата-аналар үз гаилә мөнәсәбәтләрен, шәхси тормышларын җайга салудагы кебек педагогик һәм психологик сорауларга, шулай ук балага тәрбия бирүдә ярдәмгә мохтаҗ. Шуңа күрә педагогик культура һәм ата-аналарның тәрбияче күзлегеннән максатчан тәрбия алып барулары аларга ышанычсызлыкны җиңәргә, үз чиратында, аларга шәхси тормышларын җайларга, тормыш эшчәнлеген гуманизацияләү юлы белән балаларга тәрбия бирүне яхшыртырга; гаиләдә һәм җәмгыятьтәге тискәре социаль күренешләрне киметергә һәм кисәтергә ярдәм итәчәк.

Кулланылган әдәбият

1. Фәхреддин Р. Адабе тәгълим (Укыту кагыйдәләре). Гыйлем әхлактән. Тугызынчы кисәк. Икенче басма. Казан: Академия познания, 2006. 168 б.
2. Мудрость воспитания: Книга для родителей / сост. Б.М. Бим-Бад, Э.Д. Днепров, Г. Б. Корнетов. 2-изд., доп. М.: Педагогика, 1989. 304 с.
3. Голованова Н.Ф. Социализация и воспитание ребенка: учебное пособие. Москва; Вологда: Инфра-Инженерия, 2021. 252 с.
4. Сластенин В.А., Исаев И.Ф., Шиянов Е.Н. Педагогика: учеб. пособие для студ. высш. пед. учеб. заведений / под ред. В.А. Сластенина. М.: Издательский центр «Академия», 2007. 576 с.
5. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия теориясе һәм методикасы. Социаль педагогика: югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы. Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2015. 367 б.

References

1. Fəkhreddin R. Adabe təg»lim:ukytu kagyidələre. *Gyilem əkhlaktən= The doctrine of morality.* 2nd ed. Kazan: Akademiya poznaniya; 2006. 168 p. (In Tatar).
2. Bim-Bad BM, Dneprov EHD, Kornetov GB. *Mudrost' vospitaniya: Kniga dlya roditelei=The wisdom of education: a book for parents.* 2nd ed. Moscow: Pedagogika; 1989. 304 p. (In Russ.).
3. Golovanova NF. *Sotsializatsiya i vospitanie rebenka: uchebnoe posobie=Socialization and upbringing of a child: a textbook.* Moscow; Vologda: Infra-Inzheneriya; 2021. 252 p. (In Russ.).
4. Slastenin VA, Isaev IF, Shiyanov EN. *Pedagogika=Pedagogy.* Slastenin VA. (ed.) Moscow: Academy Publishing Center; 2007. 576 p. (In Russ.).
5. Khuziakhmetov AN. *Tərbiya teoriyase həm metodikasy. Sotsial' pedagogika: yugary həm makhsus urta uku iortlary өchen lektsiyalər kursy=Theory and methodology of education. Social pedagogy.: a course of lectures for higher and secondary specialized educational institutions.* Kazan: Kazan University Publishing House; 2015. 367 p. (In Tatar).